РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

Исполнительный комитет
Ильбяковского сельского поселения
Азнакаевского
муниципального района

ул. А.Валеева, д. 50, Азнакаевский район,
с .Ильбяково, 423338,
тел./факс (885592)38-5-38
E-mail: ilb.Azn@tatar.ru

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

Азнакай муниципаль районы
Илбәк авыл җирлеге
башкарма комитеты

Ә.Вәлиев ур., 50 йорт, Азнакай районы,
Илбәк авылы, 423338
тел./факс (885592)38-5-38
E-mail: ilb.Azn@tatar.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**«13» ноябрь 2023 ел** **№ 5**

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Илбәк авыл җирлеге Тырыш торак пунктында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын үткәрү турында

2003 елның 06 октябрендәге №131-ФЗ «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьясы, 2004 елның 28 июлендәге №45-ТРЗ «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Азнакай муниципаль районы Илбәк авыл җирлеге Уставының 15.1 статьясы нигезендә, Азнакай муниципаль районы «Илбәк авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге башлыгы карар итә:

1. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Илбәк авыл җирлеге Тырыш торак пунктында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыены 2023 елның 25 ноябренә билгеләргә.

1.2. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Илбәк авыл җирлеге Тырыш торак пунктында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча халык җыенын оештыручы – Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Илбәк авыл җирлеге Башкарма комитеты;

- гражданнар җыенын үткәрү вакыты – 2023 елның 25 ноябре 11.00 сәг тән 12.00 сәг кә кадәр;
- үткәрү урыны – Тырыш бистәсе, Ноябрьнең 70 еллыгы урамындагы 1нче йорт яны торриториясе дип билгеләргә.

1.3. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Илбәк авыл җирлеге Башкарма комитетына тәкъдим итәргә:

- 2023 елның 15 ноябреннән дә соңга калмыйча гражданнарга Илбәк авылы, Ә.Вәлиев урамы, 50 йорт адрес буенча урнашкан, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Илбәк авыл җирлеге Башкарма комитетында һәм Тырыш бистәсе, Ноябрьнең 70 еллыгы урамындагы 1нче йорт адресы буенча

урнашкан мәгълүмат стендында гражданнар җыены карарына чыгарыла торган материаллар белән танышу хокукын бирергә;

- Тырыш торак пунктында сайлау хокукына ия булган яшәүчеләр исемлеген төзергә;

- гражданнар җыенына мәгълүмати материаллар әзерләргә;

- массакүләм мәгълүмат чараларында һәм башка ысуллар белән Тырыш торак пункты халкына гражданнарның җыены турында хәбәр итәргә.

2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«Сез 2024 елда 1төркем инвалидларыннан, Бөек Ватан сугышы ветераннарыннан һәм катнашучылардан, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннарыннан, көндезге уку формасында укучы студентлардан тыш, Илбәк авыл җирлеге Тырыш торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 600 сум күләмендә, 2 төркем инвалидларыннан, 80 яшьтән өлкән пенсионерлардан, күп балалы гаиләләрдән бер тапкыр түләтүне 300 сумга киметеп, үзара салым кертү һәм бу акчаларның җирле әһәмияткә ия булган түбәндәге сорауларны хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

- Тырыш торак пункты чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын ремонтлау, карап тоту (Тырыш авылындагы юлларны кардан чистарту; вак ташны сатып алу, ташу, Октябрьнең 70 еллыгы урамына вак ташны җәю, эшкә килешү буенча түләү, тракторчыга хезмәт хакын түләү)).

«РИЗА» «КАРШЫ»

3. Әлеге карарны кабул ителгәннән соң 10 көн эчендә «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталы»нда түбәндәге веб-адрес буенча: http://pravo.tatarstan.ru, Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында түбәндәге веб-адрес буенча: http://aznakaevo.tatarstan.ru һәм Тырыш бистәсе, Октябрьнең 70 еллыгы урамы, 1 йорт адресы буенча урнашкан мәгълүмат стендында урнаштырырга.

4. Әлеге карар ул халыкка игълан ителгән көннән үз көченә керә.

Башлык Р.К.Галимҗанова